РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
Татарско-Шуганского сельского поселения Азнакаевского муниципального района

ул. Советская, д. 41в , село Татарский Шуган, Азнакаевского муниципального района, 423327
Тел. (факс) (85592) 36-1-41
Tshug .Azn @tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл жирлеге Советы
БАШЛЫГЫ

Совет урамы, 41в, Татар Шуган авылы, Азнакай муниципаль районы, 423327
Тел. (факс) (85592) 36-1-41
Tshug .Azn @tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «01 » ноября 2022ел №4

Азнакай муниципаль районы «Татар-Шуганы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм
тозелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында
проект буенча ачык тыңлаулар билгеләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31 статьясф, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль берәмлегенең «Татар-Шуганы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Азнакай муниципаль районы авыл җирлегендә ачык тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар-Шуганы авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 гыйнварындагы 87 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Татар-Шуганы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты (29.11.2016ел 46,04.09.2017 ел 65,03.07.2018 104,19.03.2019 ел 131,28.02.2020 ел 166,11.08.2021 ел 35 номерлы карарлар редакциясендә) буенча ачык тыңлаулар билгеләргә (1 нче кушымта).

2. Билгеләргә:

- ачык тыңлауларны оештыручыны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар-Шуганы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү пректын әзерләү комиссиясен;
- уздыру вакыты – 2022 елның 03 ноябреннән 2022 елның 01 декабренә 17 сәгатьтән 18 сәгатькадәр;
- уздыру урыны: Татар-Шуганыавылы, Совет ур. , 41б й.;

- тикшерелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә ала торган адрес: Татар-Шуганы авылы, Совет ур., 41в й. , Азнакай муниципаль районы Татар-Шуганы авыл җирлеге башкарма комитеты.

4. Азнакай муниципаль районы Татар-Шуганы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү пректын әзерләү комиссиясенә тәкъдим итәргә:

- гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Татар-Шуганы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;

- ачык тыңлауларны уздыру нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә;

- Татарстан Республикасы Азнакай мунициипаль районының « Татар-Шуганы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Татар-Шуганы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru/.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http//aznakayevo.tatar.ru/.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Хэертдинов М.Ш.